№ 22 (1149), 26 май 2012 ел
Бердәмлек 8

ул – җәмгыятьнең кечкенә бер өлеше. Бер җитәкче, бер башлык булмаса, ул таралуга сәбәп булачак. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә ирне гаиләдә башлык-җитәкче итеп куйган. Чөнки ир кеше һәрьяктан бу урынга лаектыр. Гаиләнең бөтен сарыфы аның кайгыртуында. Әмма бу лаеклык бер үк вакытта җаваплылык белән үрелә. Чөнки сүрәнең 19 нчы аятендә әйтелгәнчә: *«Хатыннар белән лаеклы рәвештә яшәгез».* Бу аятькә өстәмә буларак, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең: *«Сезләрнең яхшыларыгыз хатыннарыгызга яхшы булганыгыз», «Хатыннар хосусында Аллаһыдан куркыгыз»* дигән мәгънәдәге күрсәтмәләре күп.

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

# Дөнья — ахирәткә әзерләнү урыны

Аллаһы Тәгалә «Әәл Гыйммран» сүрәсендә әйтә ки: *«Зәгыйфьлек, көчсезлек күрсәтмәгез, хәсрәткә бирелмәгез. Әгәр Аллаһыга ышанган булсагыз, җиңүчеләр сез буласыз».*

Иман – кеше өчен иң әһәмиятле, сүзләр белән тасвирлана алмаслык дәрәҗәдәге өстенлек. Аллаһы Тәгалә иманлы булуны тере булуга охшата, имансызлык үлемне хәтерләтә, һәм шулай ук иман белән өмет бер-берсеннән аерылмый. Иманлы кеше– иң өметле кеше! Чөнки иманы аркылы ул Иң Бөек Затка – Аллаһыга багълана. Аның өчен Аллаһы – иң рәхмәтле, иң мәрхәмәтле, тәүбәләрне, үкенүләрне кабул итүче. Аның өчен Аллаһы – гөнаһларны кичерүче, начарлыкларны яхшылыклар белән алмаштыручы, иң якын булучы һәм хакыйкый көч иясе. Иманлы кеше Аллаһының куркуны иминлеккә, көчсезлекне куәткә алмаштырганын белә. Аллаһы Тәгалә «әс-Саффат» сүрәсендә әйтте: *«Ант ки, пәйгамбәрлек белән җибәрелгән колларыбыз турында шул сүзебез үтте: алар, әлбәттә, җиңәчәкләр һәм безнең гаскәребез, һичшиксез, җиңүчеләр!»*

Иманлы кеше чирләсә дә, өметсезлеккә бирелмәс, чөнки аңа Аллаһы аятьләрендә таяныч бар. «Әш-Шугара» сүрәсендә әйтелә ки: *«Раббым мине юктан бар итте һәм тугры юлга күндерде. Мине ашаткан, эчерткән дә Аллаһы, чирләгән вакытымда миңа шифа бирүче дә Ул»*.

Мөэмин-мөселман хата кылса, бәндәчелеккә бирелеп, гөнаһка таба барса, шул инанудадыр ки: *«Әйт ки үзләренә, әй золым кылган һәм гөнаһ эшләгән колларым, Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез! Аллаһы бөтен гөнаһларны да гафу итә! Ул бөек, мәрхәмәтле»* («әз-Зумәр» сүрәсе, 53 нче аять).

Инанган кеше өчен гел җиңеллек бар. Чөнки Аллаһы «әл-Инширах» сүрәсендә әйтте: *«һәм чынлыкта авырлыктан соң җиңеллек бар»*. Бу аять мөэминнең таяныч чыганагы.

«Әл-Бәкара» сүрәсенең 156-157 нче аятьләрендә әйтелә: *«Без Аллаһыныкы һәм Аңа кайтабыз. Аларга Аллаһыдан гафу ителү, рәхмәт бар һәм алар тугры, һидаять юлында».* Бу аятьләр исә мөэмин өчен өмет һәм гайрәт чыганагы.

Иманлы кеше дошманлыкны солых белән чишәр, нәфрәтнең беркөнне сөюгә әйләнүенә инаныр. «Әл-Мумтәхәна» сүрәсендә әйтелә: *«Өмет ителә ки, Аллаһы сез һәм сезнең белән дошманлык кылучылар арасында дуслык барлыкка китерер».*

Мөэминнәр картаеп, һәрьяктан көчсезләнеп, чәчләре агарса да, өметләрен өзмәсләр. Аллаһы Тәгалә шул ук «Мәрйәм» сүрәсендә әйтә: *«Гаден җәннәтләре, Аллаһы аларны яшерен буларак колларына вәгъдә итте. Аның вәгъдәсе хак. Анда буш сүз ишетмәсләр, сәламнән башка. Иртә һәм кич ризыклары китерелер»*.

Бу инану, бу рәвештәге Иманлы кеше дошманлыкны солых белән чишәр, нәфрәтнең беркөнне сөюгә әйләнүенә инаныр. «Әл-Мумтәхәна» сүрәсендә әйтелә: *«Өмет ителә ки, Аллаһы сез һәм сезнең белән дошманлык кылучылар арасында дуслык барлыкка китерер».*

Бу инану, бу рәвештәге иман авырлыкта сабырлыкны, кыенлыкта җиңеллекне, тынгысызлыкта тынычлыкны, ялгызлыкта дуслыкны барлыкка китерер. Мондый кеше золымга таба булганда Аллаһыга сыеныр, ярдәм теләр. Аның тормышы өметсезлек эчендәге караңгылыкка әйләнмәс.

Аллаһы Тәгалә Китабында әйтте: *«Әй, иман китергәннәр! Аллаһыдан куркыгыз! Һәм һәркем иртәгәсе өчен (ахирәт өчен) ни хәзерләгәнен карасын. Аллаһыдан куркыгыз! Чынлыкта Аллаһы ни кылганнарыгызны белә»* («әл-Хәшер» сүрәсе).

Аллаһы Тәгалә аятьләрендә иман китергәннәргә галәмнең, мәхлукларның, кешенең ахырын белдерде. Кыямәт көненең киләчәген, бу галәмнең бер әсәре дә калмаячагын, Үзе безгә вәгъдә иткән ахирәт тормышының башланачагын ирештерде, безләрнең аңа әзер булуыбызны теләде.

Башка бер аятьтә исә: *«Алар ул бөек көндә (ахирәт көнендә) терелтеләчәкләрен акылларына китермиләрме? Менә ул көнне кешеләр Раббылары хозурына чыгачаклар»,* – диелә.

Аллаһы бу аятьтә хакыйкый булган ахирәтне, фаный дөнья тормышын, үлемне һәм яңадан кубарылуны безгә җиткерде. Белдерә ки, бөек көнне барчасы да Аллаһы хозурында хисап тотачак.

Дөнья тормышы хакында Аллаһы Тәгалә



болай дип белдерә: *«Бу дөнья тормышы бары тик күңел ачудан, бер уеннан гыйбарәт. Ахирәт йорты – менә ул хакыйкый тормыш. Белсәләр иде».*

Иман китергәннәр бу дөньяның ахирәткә хәзерләнү урыны булганлыгын, гомернең, тормышның бу әзерлек өчен бер кыйммәтле хәзинә икәнен һич тә онытмый. Алар Аллаһының әмерләренә һәм тыюларына тәслим булып (каршылыксыз тану), ахирәттә бәхетле булу юлларын эзләргә тырыша, бу дөньяның алдатучы һәм фани булганлыгына төшенә. Аллаһы Тәгалә «әл-Кәһеф» сүрәсендә әйтә ки: *«Мал һәм балалар – дөнья тормышының зиннәтләре. Ахирәт өчен калучы изге гамәлләр исә Раббың катында һәм савап ягыннан, һәм өмет баглау ягыннан тагын да лаеклырак».*

Мөэмин бу фани дөнья тормышында үлемне һәм ахирәтне онытмас. Ул Аллаһының әмерләрен үтәр һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте буенча яшәп, ахирәткә әзерләнер. Гамәлләрен хисап кылыр, нәфесен контрольдә тотар. Үзенә бирелгән һәртөрле нигъмәттән соралачагын онытмас, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисендә сыйфатлаган акыллы кеше булырга теләр. Пәйгамбәребез фикеренчә акыллы кеше кем соң? Ул әйтте: *«Акыллы шул ки, кем үзенең нәфесен тыйды, хисап итте һәм үлемнән соң булган нәрсәләр өчен тырышлык күрсәтте».*

**Алмаз ЯКУПОВ.**
*(«Ислам нуры»)*

# Язмышка ышану хакында

Язмыш, тәкъдир - дөньяның әүвәленнән ахырына кадәр дөньяда булачак эшләрнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан беленүе ул. Язмыш,тәкъдир - көч җитү, планлаштыру, бар нәрсәне үлчәп эш итү, һәрнәрсәнең шәкелен һәм үзенчәлеген билгеләү, кадерен белү дигән сүз. Коръән-Кәримдә 100 дән артык урында тәкъдир һәм тәкъдир белән бәйле гыйбарәләр бар. Бу гыйбарәләрдә күбрәк үлчәм һәм план мәгънәләре алгы планга чыга. Бу вәзгыятькә күрә, Аллаһының бар нәрсәне максатка ярашлы рәвештә һәм билгеле бер үлчәмгә салып яралтуына язмыш диелә. Мәсәлән, ай һәм кояш хәрәкәтләреннән туган вакытның исәпләнүе, кешеләрнең яралтылуы, ризыклары, яшәячәк гомерләре һәм үлем көннәре язмыш белән билгеләнә. Дөньяда бар нәрсә дә үлчәмгә салынган. Бу хакта “Рәгыд” сүрәсенең 8 нче аятендә: *“Аллаһының һәр эше төгәл үлчәнгән”,* – диелә. Язмыш мәсьәләсе белән бәйле буларак, Аллаһының кайбер сыйфатларын хәтерләтеп китү кирәк. Язмышка ышануның ирадә, кодрәт һәм гыйлем сыйфатлары белән элемтәсе бар.

Аллаһының бар нәрсәне белүе - аның гыйлем сыйфаты; Аллаһының теләгәнен эшләве - аның ирадә сыйфаты; Аллаһының һәр нәрсәгә көче җитүе - аның кодрәт сыйфаты.

Аллаһы иксез-чиксез ирадәсе һәм гыйлеме белән бар нәрсәне үзе теләгәнчә башкару көченә ия. Моның белән бергә Аллаһы югарыда санап кителгән сыйфатларны чикләнгән хәлдә генә булса да кешеләргә дә биргән. Кеше дә белә, тели, сорый һәм башкара. Аллаһы кешегә үз тормышы белән бәйле карарлар кабул итә алачак аңлау сәләте, акыл биргән. Үзенә бирелгән акыл белән кеше үз карарларын үзе билгели ала.

Акыл кешегә җаваплылык та йөкли. Аллаһы кешене ирекле итеп яралткан. Кеше үзе сайлаган юллар белән тормышын дәвам иттерә. Аллаһы Тәгалә үзенә ышанып-ышанмау мәсьәләсендә дә кешене ирекле калдыра. Кеше Аллаһыга ышанып һәм аның үгет-нәсыйхәтләрен тыңлап, үтәп яшәсә, җәннәтне казаныр. Киресенчә булса, җәһәннәмгә лаек булыр.

Кеше барлык гамәлләрен аңлы рәвештә тормышка ашыра. Кеше сайлап алу мөмкинлегенә ия булганга күрә, сайлап алынган юлның нәтиҗәләренә дә риза булырга тиеш. Әлеге вәзгыять Коръән-Кәримдә түбәндәге аятьләрдә ачыклана:

*“Кылган гамәлләреннән һични дә киметмәдек, һәркем үз гамәлләренең тоткыны”.* (“Тур” сүрәсе, 21 нче аять). *“Кеше игелек кылса, үз файдасына; яманлык кылса, үзенең зарарына кылыр”* (“Бәкара” сүрәсе, 286 нчы аять).

Кеше файдалы гамәлләр башкару өчен тырышырга һәм Аллаһыдан ярдәм сорарга тиеш. Башына берәр төрле хәл килгәндә *«Шулай эшләсәм, болай булыр иде»,* - димәскә, Аллаһының тәкъдире шулайдыр дип әйтергә кирәк. Аллаһының тәкъдиренә ышанучы кеше гомер буе хозурлы булыр. Язмышка ышанган кеше иртәгә ни булыр дип уйга калу, шиккә төшү куркуы булмаганга күрә, күңеле тыныч булыр. Тәкъдиргә ышанучы үткән көннәрендә хаталары булса, алардан тәүбә итеп, ялгышларны кабатламау форсаты булуын да аңлар. Язмышка ышанган кеше ризыгының да Аллаһы тарафыннан билгеләнүен белер, мөмкинлекләренә, сәләтенә туры килгән эштә эшләр, ихтыяҗларын канәгатьләндерер. Башкарылырга тиешле эшләрне җиренә җиткергәннән соң, Аллаһының үзе өчен иң яхшысын бирәчәгенә ышаныр. Ягъни Аллаһыга чиксез ышаныр һәм аңа таяныр.

Аллаһының ярдәменә ышану, Аның ярдәменнән өмет өзмәү, буйсынучан булу - кешенең кулыннан килгәнне башкарганнан соң, нәтиҗәне Аллаһыдан көтү дигән сүз. Монда төп мәсьәлә - кешенең җаваплылык тоеп, башкарылырга тиешле эшләрне җиренә җиткерүе. Эшләмичә, тырышмыйча Аллаһыга ышану булмас. Ялкауланып, Аллаһыга сыену да дөрес түгел. Кулыңнан килгәнне эшләмичә, башына килгән хәлләргә “Нишлим, язмышым шундыйдыр”, - дип әйтү дөрес булмас. Язмышка ышанучы кеше үлеменең дә үзе белмәгән бер вакытта киләчәгенә дә ышаныр. Бу рәвешле гомеренең матур итеп узуын теләгән кебек, үлеменең дә бу шәкелдә хәерле үлем булуын